Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

13 ноябрь, 2019 ел № 3

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Кибәч авыл җирлеге Кибәч авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә:

Халык җыенын ике этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2019 елның 27 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Үзәк урамы, 1А йорт адресы буенча урнашкан күпфункцияле үзәк бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Куйбышев, Кооператив, Пролетарий урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2019 елның 4 декабрендә 14 сәгать 00 минутта Үзәк урамы, 1А йорт адресы буенча урнашкан күпфункцияле үзәк бинасында үткәрергә. Гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә Бөһар, Киров, Пионер, Үзәк урамнары буенча теркәлгән кешеләрне кертергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2020 елда Кибәч авыл җирлеге Кибәч торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 төркем инвалидларын, көндезге уку формасы студентларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау;
- гомуми файдаланудагы урыннарны төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Кибәч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге башлыгы — Р.Ә. Рәимов